СОВЕТ МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ СОВЕТЫ

---

**Карар** **Решение**

№ 10-15 «11» август 2022 ел.

Татарстан Республикасы «Мамадыш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 10-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, һәм Татарстан Республикасы «Мамадыш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставын гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советының 2018 елның 29 июнендәге 6-27 номерлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы «Мамадыш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына кушымта нигезендә үзгәрешләр кертергә.
2. Әлеге карарны законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә җибәрергә.
3. Әлеге карарны, дәүләт теркәвенә алынганнан соң, Мамадыш муниципаль районының mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.
4. Әлеге карар «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясындагы 8 өлеше, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге уставының 90 статьясындагы 2 өлеше нигезләмәләрен исәпкә алып рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны район Советының регламент, законлылык, хокук тәртибе һәм депутат этикасы буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Район башлыгы,
муниципаль район
Советы рәисе А.П.Иванов

Мамадыш муниципаль район
Советы карарына 1 нче кушымта
11.08.2022 ел, № 10-15

Татарстан Республикасы «Мамадыш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына кертелә торган үзгәрешләр

1. «Районның җирле әһәмияттәге мәсьәләләре» 6 статьясындагы 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 9.1 пункт өстәргә:
«9.1) шәһәр һәм авыл торак пунктларыннан читтәге Район чигендә беренчел янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү;»;
2. «Районның җирле әһәмияттәге мәсьәләләре» 6 статьясындагы 1 өлешенең 36 пунктында «, ясалма җир кишәрлеге төзү турында шартнамә төзү хокукына ачык аукцион үткәрү» сүзләрен төшереп калдырырга;
3. «Районның җирле әһәмияттәге мәсьәләләре» 6 статьясындагы 2 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 11.1, 11.2 пунктлар өстәргә:
«11.1) җирлекнең торак пунктлары җирләрендә урнашкан кишәрлек урманчылыклары составындагы урманчылыкларны төзү, бетерү, аларның чикләрен билгеләү һәм үзгәртү турында, шулай ук җирлекнең торак пунктлары җирләрендә урнашкан урманчылыкларның урман хуҗалыгы регламентларын эшләүне һәм раслауны гамәлгә ашыру турында карарлар кабул итү;
11.2) җирлекнең торак пунктлары җирләрендә урнашкан урманнарга карата урман корылышы чараларын гамәлгә ашыру;»;
4. «Районның җирле әһәмияттәге мәсьәләләре» 6 статьясындагы 2 өлешенең 21 пунктында «, ясалма җир кишәрлеге төзү турында шартнамә төзү хокукына ачык аукцион үткәрү» сүзләрен төшереп калдырырга;
5. «Районның җирле әһәмияттәге мәсьәләләренә кертелмәгән мәсьәләләрне хәл итүгә хокукы» 7 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 17 пункт өстәргә:
«17) муниципаль янгын сагын булдыру.»;
6. «Район башкарма комитеты вәкаләтләре» 44 статьясындагы 1 өлешенең 7 пунктын түбәндәге эчтәлекле 14 абзац өстәргә:
«-шәһәр һәм авыл торак пунктларыннан читтәге Район чигендә янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итә;»;
7. «Район башкарма комитеты вәкаләтләре» 44 статьясындагы 2 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 17 абзац өстәргә:
муниципаль янгын сагын булдыра.”;
8. «Район башкарма комитеты вәкаләтләре» 44 статьясындагы 1 өлешенең 3 пунктының 13 абзацында «, ясалма җир участогы төзү турында шартнамә төзү хокукына ачык аукцион үткәрә» сүзләрен төшереп калдырырга;

9. 44 статьяның 1 өлешендәге 9 пунктының 23 абзацында. Район Башкарма комитеты вәкаләтләре «, ясалма җир кишәрлеге төзү турында шартнамә төзү хокукына ачык аукцион үткәрә» сүзләрен төшереп калдырырга;
10. Район Башкарма комитетының 44 статьясындагы 1 өлешенең 9 пунктын түбәндәге абзацлар белән тулыландырырга:
«җирлекнең торак пунктлары җирләрендә урнашкан кишәрлек урманчылыклары составында төзелә торган урманчылыкларны төзү, бетерү, аларның чикләрен билгеләү һәм үзгәртү турында, шулай ук җирлекнең торак пунктлары җирләрендә урнашкан урманчылыкларның урман хуҗалыгы регламентларын эшләүне һәм раслауны гамәлгә ашыру турында карарлар кабул итү;
-җирлекнең торак пунктлары җирләрендә урнашкан урманнарга карата урман корылышы чараларын гамәлгә ашыру;».